ГЛАВА
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Красавина, д.40, с. Набережные Моркваши,
422594

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ
Красавин ур., 40 нчы йорт, Яр Буе Морквашы авылы,
422594

Тел.: (84379) 3-16-47, факс: (84379) 3-16-47.

03.12.2021 № 1

На №______________от________________

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Десятидворка авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Десятидворка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза буласызмы? " мәсьәләсе буенча 2021 елның 3 декабрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Десятидворка бистәсендә урамнарны яктыртуны реконструкцияләү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашкан 5 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 3 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен тавыш бирде 3 халык җыенында катнашучы; «Юк» позициясе өчен тавыш бирде 0 җыенда катнашучы.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Десятидворка авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танылды.

2 «Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге Десятидворка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты карары белән билгеләнгән ташламалы категориядән тыш, балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза буласызмы? " дигән сорау буенча карарны таныргa:

Десятидворка бистәсендә урамнарны яктыртуны реконструкцияләү.

3. Югары Ослан муниципаль районы Яр буе Морквашы авыл җирлегендә халык җыенының нәтиҗәләрен Яр буе Морквашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгына әлеге карарны җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: И.Х.Гаязов